ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.10.2018 Казан ш. № 6-170/тп

«Интеграция» чиктәш җылылык челтәре компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына кушкан (технологик тоташтырган) өчен кушыла торган җылылык йөкләнешенең бер берәмлек куәтенә исәпләп чыгарылган түләүне билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «Җылылык белән тәэмин итү системаларына кушу (технологик тоташтыру) турында, җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәт күрсәтүләреннән һәркемнең дискриминациясез файдалана алуы турында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм үз көчләрен югалтуларын тану хакында» 2018 елның 5 июлендәге 787 нче номерлы карарлары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Интеграция» чиктәш җылылык челтәре компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына кушкан (технологик тоташтырган) өчен түләүне, әгәр гариза бирүче объектының кушыла торган җылылык йөкләнеше, 0,1 Гкал/сәг күбрәк булып, 1,5 Гкал/сәг артып китмәсә, кушыла торган җылылык йөкләнешенең бер берәмлек куәтенә исәпләп, әлеге карарга кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән түләү 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәиснең беренче урынбасары А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 26 октябрендәге 6-170/тп
номерлы карарына кушымта

«Интеграция» чиктәш җылылык челтәре компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына кушкан (технологик тоташтырган) өчен, әгәр гариза бирүче объектының кушыла торган җылылык йөкләнеше, 0,1 Гкал/сәг күбрәк булып, 1,5 Гкал/сәг артып китмәсә, кушыла торган җылылык йөкләнешенең бер берәмлек куәтенә исәпләп чыгарылган түләү

мең сум/Гкал/сәг

| т/б № | Исеме | Күрсәткеч |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүчеләрнең объектларын кушу буенча гамәлләр үткәрү чыгымнары ($П_1$) | 6,678 |
| 2 | Гариза бирүчеләр объектларының кушыла торган җылылык йөкләнеше, 0,1 Гкал/сәг күбрәк булып, 1,5 Гкал/сәг артып китмәгәндә, гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яки җылылык энергиясе чыганакларыннан әлеге объектларны кушу ноктасына кадәр җылылык челтәрләрен (җылылык пунктларын төзүдән (реконструкцияләүдән) тыш) төзү (реконструкцияләү) чыгымнары, ($П_{2.1}$), шул исәптән: | - |
| 2.1 | Җир өстеннән (җир астыннан) сузу | |
| 2.1.1 | 50 - 250 мм | - |
| 2.1.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.1.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.1.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм зуррак | - |
| 2.2 | Җир астыннан сузу, шул исәптән: | |
| 2.2.1 | канал ясап сузу | |
| 2.2.1.1 | 50 - 250 мм | - |
| 2.2.1.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.2.1.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.2.1.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм зуррак | - |
| 2.2.2 | каналсыз сузу | |
| 2.2.2.1 | 50 - 250 мм | 2 898,733 |
| 2.2.2.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм зуррак | - |
| 3 | Гариза бирүчеләр объектларының кушыла торган җылылык йөкләнеше, 0,1 Гкал/сәг күбрәк булып, 1,5 Гкал/сәг артып китмәгәндә, гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яки җылылык энергиясе чыганакларыннан әлеге объектларны кушу ноктасына кадәр җылылык пунктларын төзү (реконструкцияләү) чыгымнары, ($П_{2.2}$) | - |
| 4 | Табышка салым | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге